**Шәһәр Башкарма комитеты Комсомол районы хакимиятенең 2022 елдагы эшчәнлеге йомгаклары һәм 2023 елга бурычлары**

Хисап чорында район хакимиятенә гражданнардан **782** мөрәҗәгать керде, бу 2021 елга караганда **241**гә кимрәк (2021 елда – 1023).

«Халык контроле» дәүләт мәгълүмат системасы елдан-ел киңрәк популярлык ала. Әлеге система аша хакимияткә **1548** хәбәр алынды (2021 елда - 980). Хәл ителгән заявкалар өлеше **91 %ны тәшкил итә.**

Коммуникациянең шулай ук уңайлы һәм популяр ысулларыннан берсе булып социаль челтәрләр тора. Социаль челтәрләр аша 2022 елда 1321 мөрәҗәгать карап тикшерелде һәм хәл ителде.

Тормышның сыйфатын күтәрү элеккечә үк төп максат булып тора. Бу уңайдан шәһәр территориясендә күп кенә программалар тормышка ашырыла.

«Безнең ишегалды» программасы ишегалды киңлекләрен үзләштерү һәм аларны тагын да файдалырак итү буенча активрак эшләргә сәбәп бирде. Яңартылган ишегалларында уникаль һәм гадәти булмаган социаль проектлар: ачык һавада кино күрсәтү һәм музыкаль кичәләр оештыру тормышка ашырыла.

«Безнең ишегалды» Президент программасына районның 241 (ике йөз кырык бер) ишегалды территориясе керде. Программаны гамәлгә ашыру чорында 97 ишегалды төзекләндерелде, шул исәптән 37се – 2022 елда. 2023 елга кимендә 44 ишегалдын төзекләндерү планлаштырыла.

2023 елның 1 гыйнварына районның торак фонды 588 күпфатирлы йорт һәм шәхси сектордагы 3536 йортны тәшкил итә. Узган елда 24 яңа йорт файдалануга тапшырылды.

31 торак йортта 300 миллион сумлык капиталь ремонт эшләре башкарылды. Программаны тормышка ашыра башлаган 2008 елдан бирле район торак фондын ремонтлауга 3 млрд. сумнан артык акча җәлеп ителгән.

Шәһәрдә социаль инфраструктура объектларын үстерүгә зур игътибар бирелә. Әйтик, 2022 елда «Притяжение» торак комплексында 85 нче «Карусель» балалар бакчасы үз ишекләрен ачты (189 бала йөри). Агымдагы елда әлеге торак комплексында 1500 урынга исәпләнгән мәктәп төзеләчәк.

Республика программалары буенча шулай ук:

- «Төзүче» стадионына капиталь ремонт ясалды;
- «Чишмә» халыклар дуслыгы йорты бинасын капиталь ремонтлау төгәлләнде;
- 6 нчы һәм 44 нче мәктәпләрдә ашханәләр капиталь ремонтланды.

2023 елда мәгариф учреждениеләрен капиталь ремонтлау дәвам итәчәк. 44 нче һәм 56 нчы мәктәпләрне ремонтлау планлаштырыла.

Узган еллардагы кебек үк, шәһәрнең юл инфраструктурасына да зур игътибар бирелә.

2022 елда юл төзелеше программаларының төп объекты булып Мәләкәс елгасы аша күпер төзелеше белән Гостев урамын реконструкцияләү торды, күпер Замелекесье микрорайонын ГЭС поселогы белән тоташтыра.

Замелекесьеда да яңа юл барлыкка килде. Авангардная урамының 20 микрорайон ягыннан дәвамы төзелде.

Бакчачылык берләшмәләренә ярдәм күрсәтүнең республика программасы кысаларында «Гидротөзүче» бакчачылык ширкәтенә 66 млн. сумга асфальт юл салынды. Әлеге бакчачылык ширкәте 2018 елдан башлап керү юллары ремонтланган шундый бишенче ширкәт булды.

Сезгә тәкъдим ителгән фильмнан күренгәнчә, быел юл эшләренең төп объекты – Мәскәү проспектының дәвамы төзелеше. Орловка кырында «Притяжение» торак комплексы районында проспектның Челнинка елгасы аша күпер кичүенең яңа өлешен төзү эшләре бара.

Шулай ук юл төзелеше программасы кысаларында Гидротөзүчеләр урамында юлга капиталь ремонт үткәрү планлаштырылды. «Энергетик» мәдәният сарае тукталышында җәяүлеләр өчен юл белән җир асты кичүе ремонтланачак. Хәзерге вакытта проект эшләре бара.

Җирле әһәмияттәге мөһим мәсьәләләрне хәл итү күбесенчә халыкның турыдан-туры катнашында башкарыла. Халыкны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тартуның иң нәтиҗәле механизмнарының берсе булып территориаль иҗтимагый үзидарәләр тора. Безнең районда 250 актив кеше җәлеп ителгән 26 территориаль җирле үзидарә органы бар.

«Татарстан Республикасының иң яхшы территориаль иҗтимагый үзидарәсе» конкурсы территориаль иҗтимагый үзидарәләргә ярдәм күрсәтүнең бер алымы булып кала. 2022 елда 9 территориаль иҗтимагый үзидарә рәисе 3 млн 738 мең сум грантка ия булды.

Территорияләрне төзекләндерү шәһәр кешеләренең комфортлылыгын, тормыш сыйфатын һәм уңайлылыгын формалаштыра. Без барыбыз да чиста, тәртипле районда яшәргә телибез. Территорияне төзекләндерү буенча язгы һәм көзге айлыкларны уздыру чорында районның барлык уку йортлары, мәктәпләре, предприятиеләре, оешмалары актив катнашты.

Катнашучыларның гомуми саны 36 меңнән артык кешене тәшкил итте. Район территориясен төзекләндерү һәм инфраструктураны үстерү буенча эш дәвам итәчәк.

3500 кубометр чүп-чар җыелды һәм чыгарылды, 18 санкцияләнмәгән чүплек бетерелде. 13 меңнән артык агач һәм куак утыртылды. 6 мең агач һәм куаклар санитар киселде.

Без үз чиратыбызда, шәһәрне төзекләндерү һәм җәмәгать тәртибе кагыйдәләрен үтәүне контрольдә тотабыз. Шулай итеп, хезмәткәрләр тарафыннан 1620 административ материал төзелде, салынган штрафлар күләме 3 миллион сумнан артыкны тәшкил итте. Мәҗбүри таләпләрне үтәү өчен закон нигезендә 150 дән артык рейд чарасы үткәрелде:

- хезмәт килешүләрен рәсмиләштермичә эшләүче затларны ачыклау буенча;

- җәйге һәм кышкы чорда су объектларында гражданнарның кагыйдә бозуларын ачыклау буенча;

- законлы булмаган сәүдә итүгә каршы көрәш буенча.

Полиция вәкилләре белән берлектә сәүдә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләрендә алкогольле продукция сату кагыйдәләренең үтәлешен тикшерү буенча 33 рейд уздырылды. Хокук бозуларның 30 очрагы ачыкланды. 2022 елда законсыз урнаштырылган 25 стационар булмаган объект демонтажланды.

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә район хакимияте гражданнарның якланмаган, аз керемле категорияләренә аерым игътибар бирү бурычын куя.

*Хисап елында:*

- *Аз керемле гаиләләрдән 95 бала сәламәтләндерү лагерьларына һәм шифаханәләренә юлламалар алды.*

- *Аз керемле гаиләләрдән булган 971 балага Яңа ел бүләкләре тапшырылган чыршы бәйрәме оештырылды.*

*«Мәктәпкә җыенырга булыш» акциясе кысаларында матди ярдәм алдылар:*

- *районның **195** баласы (**253 500 мең сум**);*
- *вакытлыча күченүче гаиләләрдән **16** бала;*
- *район депутатлары тарафыннан **520** гаиләгә ярдәм күрсәтелде (**470 мең сумнан артык**).*

Соңгы вакыйгалар уңаеннан, район хакимияте эшчәнлегендә яңа юнәлеш барлыкка килде – күченеп килергә мәҗбүр булганнарга социаль ярдәм оештыру һәм махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләренә булышлык итү.

Безнең шәһәргә Донецк һәм Луганск халык республикаларыннан күченүчеләр килү сәбәпле, 1 апрельдән шәһәрдә оператив штаб төзелде, 197 шундый граждан «Жемчужина» шифаханәсенә урнаштырылды. Күченеп килүчеләргә һәрьяклы ярдәм күрсәтү өчен, шәһәрдәге хезмәтләр белән ведомствоара хезмәттәшлек җайга салынды. Район хакимияте аларның тормыш-көнкүреш шартларын тәэмин итү эшен оештырды. Хәзерге вакытта бу гаиләләр безнең социумга урнаштылар: шәһәр предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшлиләр, ә балалар мәктәпләрдә белем ала, балалар бакчаларына йөри. Бу юнәлештә эш дәвам итә.

21 сентябрьдән шәһәрдә махсус хәрби операция зонасында хезмәт итүчеләрнең гаиләләренә ярдәм күрсәтү буенча штаб төзелде. Район хакимияте хәрби операция зонасында хезмәт итүчеләрнең гаиләләре белән адреслы эш алып бара. Болар – торак-көнкүреш, медицина, социаль мәсьәләләрне хәл итү, мәдәният учреждениеләрендә үткәрелә торган чараларга чакыру.

Территориаль иҗтимагый үзидарә рәисләре дә бу эштән читтә калмады. Солдатларга гуманитар ярдәм күрсәтү һәм аны җыю буенча Комсомол районы территориаль иҗтимагый җирле үзидарә органнары рәисләре ассоциациясе зур эш алып бара. Аларның битараф булмаулары һәм күрсәткән ярдәмнәре өчен рәхмәт сүзләрен җиткерәсем килә. Гуманитар ярдәм җыюдан тыш алар шулай ук маскировка челтәрләре үрү һәм блиндажларга кую өчен шәмнәр ясау буенча пунктлар эшен оештырдылар.

Бөек Ватан сугышы ветераннары да игътибар үзәгендә булды. Бөек Җиңүнең 77 еллыгы уңаеннан **113** Бөек Ватан сугышы ветераны һәм сугышта катнашучыларның тол хатыннарына Татарстан Республикасы Президенты һәм

шәһәр Хакиме исеменнән истәлекле бүләкләр тапшырылды. **124** ветеран 95, 100 ел тулу уңаеннан юбилей даталарына котлаулар алдылар.

Шәһәрдә яшәүче 4 меңнән артык өлкән буын кешесе өчен төрле хәйрия ярдәме күрсәтелде.

Сәламәтлек мөмкинлекләре чикле кешеләр исә барлыгы 1 млн. сумнан артык хәйрия ярдәме алды.

Район халкын авыл хуҗалыгы продукциясе, көндәлек ихтыяҗда булган азык-төлек белән тәэмин итүне яхшырту максатларында **28** сезонлы авыл хуҗалыгы ярминкәсе оештырылды һәм үткәрелде. Андый ярминкәләрне халык һәрчак көтеп ала. Быел безнең ярминкәләр уза торган «Төзүче» стадионы каршындагы мәйданчыкны төзекләндерү планлаштырыла.

Хакимият эшчәнлегенең тагын бер мөһим юнәлеше – мәдәни тормышны киңрәк үстерү, районда яшәүчеләр һәм кунаклар өчен массакүләм чаралар үткәрү. Иҗтимагый киңлекләрдә ел буена **200**дән артык шундый чара үткәрелде.

Шәһәрнең яр буйларында, парклар һәм скверларда беренче тапкыр ачык һавада кино күрсәтүләр, әдәби һәм музыкаль кичәләр оештырылды. Быел да үз алдыбызга әлеге юнәлешне тагын да яхшырту һәм халыкны ял иттерү форматын киңәйтү бурычын куябыз.

2023 ел Татарстан Республикасында Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы дип игълан ителде. Шул уңайдан, район хакимияте 2023 елга өстенлекле бурычлар куя:

- барлык планлаштырылган чараларны үткәрүне тәэмин итү;
- эшне дәвам иттерү;
- халыкка социаль ярдәм күрсәтү;
- «Безнең ишегалды» программасы буенча ишегалларын төзекләндерү;
- районны төзекләндерү буенча: юлларны ремонтлау, территорияләрне яшелләндерү, йортлар, мәгариф һәм мәдәният учреждениеләре төзү һәм ремонтлау.